Personalia

DOI: 10.26907/2311-2042-2022-19-2-155-163

# INVESTING THE WARMTH OF HER SOUL… (THE 90TH ANNIVERSARY OF RESEDA GANIYEVA)

**Alfat Magsumzyanovich Zakirzyanov,**
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art,
the Science Academy of the Republic of Tatarstan,
12 K. Marks Str., Kazan, 420111, Russian Federation,
alfat_zak@mail.ru.



**Ganieva Reseda Kadyrovna** (1932–2020) was a literary critic, teacher and scientific mentor. In 1952–1958, she studied at the Faculty of the Tatar Language and Literature of Kazan State University; in 1958–1962, she did a postgraduate course at Moscow University at the Department of Peoples of the USSR. In 1962–2011,

**Ганиева Резеда Кадыйр кызы** (1932–2020) – әдәбият галиме, педагог, фәнни остаз. 1952–1958 елларда КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә, 1958–1962 елларда Мәскәү университетының СССР халыклары кафедрасы каршындагы аспирантурада укый.

Р. Ганиева 1962–2011 елларда

**Ганиева Резеда Кадыровна** (1932–2020) – литературовед, педагог, научный наставник. В 1952–1958 гг. училась на факультете татарского языка и литературы Казанского государственного университета, в 1958–1962 гг. – в аспирантуре Московского университета при кафедре народов СССР. В 1962–2011 гг. Р. Ганиева

R. Ganieva was engaged in pedagogical and scientific work at the Department of Tatar Literature of Kazan University. In 1964, she received a Candidate of Philology degree, in 1992 she was awarded a Doctor of Philology degree. She was a professor of Kazan State University (now KFU) (1993) and a professor in the Department of Tatar Literature (1993).

Her sphere of scientific interests included Literature of the Middle Ages and Modern Times, Eastern Classics, Literature of the Peoples from the Ural-Volga Region, Tukay Studies and Iskhak Studies. She was an Honored Worker of Science of the Republic of Tatarstan (1994).

Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында педагогик һәм гыйльми эшчәнлек белән шөгыльләнә. 1964 елда филология фәннәре кандидаты, 1992 елда филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә ия була. Казан дәүләт университеты (хәзер КФУ) профессоры (1993).

Фәнни хезмәтләре Урта гасыр һәм яңа заман татар әдәбияты, Шәрык классикасы, Идел - Урал буе, төрки халыклар әдәбиятлары, Тукай турындагы гыйльмият, Г. Исхакый фәне һәм башка тармакларга карый. Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1994).

занималась педагогической и научной деятельностью на кафедре татарской литературы Казанского университета. В 1964 г. снискала степень кандидата филологических наук, в 1992 г. ей присудили степень доктора филологических наук. Профессор Казанского государственного университета (ныне КФУ) (1993), профессор кафедры татарской литературы (1993).

Сфера научных интересов: литература Средневековья и Нового времени, восточная классика, литература народов Урало-Поволжья, тукаеведение, исхакиведение.

Заслуженный деятель науки РТ (1994).

From the 1960s, Prof. Reseda Ganieva, an Honored Scientist of the Republic of Tatarstan, Doctor of Philology, conducted serious research in the field of Tatar literary criticism and made a great contribution to clarifying its methodology, principles and methods, identifying new areas of research; she received wide recognition as a researcher of the literatures of the Volga and Ural peoples. The date of her 90$^{th}$ anniversary, her life and creative path, her personal qualities and scientific achievements are an opportunity to look back and determine their value in the past and in modern literary science.

R. Ganieva was born in the village of Maly Sherdan, the Zelenodolsky District, outside Kazan on November 13, 1932. When the Great Patriotic War broke out and her father Gabdelkadir went to the front, she was less than 9 years old. They were the first in the village to hear the sad news about their father’s death in one of the bloody battles for Leningrad. Widowed with four children, her mother, Khabira, did everything to protect her children from starvation, to give them an education and a profession. Being the eldest daughter, Reseda had to go through hardships of life at an early age. The bright teenage girl set big goals, never succumbing to difficulties. After graduating from a seven-year school in her native village, she entered the Kazan Pedagogical School and was recognized as one of its best students. All her life she remembered with nostalgia her teachers at the Pedagogical School, Zifa and Nail Gubaidullins, who helped her with advice during her school years; Vali Khaziev, Raziya Bayazitova and others, her mentors, who admired her as while she was their student.

With a diploma from the Pedagogical School, for several years, she taught at schools in Kazan and Mulma, the village in the Vysokogorsky District. During this period, she studied in absentia at the Department of the Tatar Language and Literature of Kazan State University. On the advice of her mentor, Prof. I. Nurullin, she entered the graduate school at the Department of Literature of the Peoples of the USSR at Moscow University and began to study the theme of satire in G. Tukay’s work. Here, R. Ganieva discovered a new world. Listening to the lectures, delivered by her scientific adviser Madina Iskanderovna Bogdanova, as well as the famous scientists of the department I. Braginsky, Kh. Ker-Ogly, A. Klimovich, R. Bikmukhametov, A. Zainetdinov, Sharaf and others, and being in constant communication with them expanded her scientific horizons and range of interests. Thanks to her fellow students and the study of Bashkir, Chuvash, Kyrgyz, Azerbaijani, Komi and Yakut literatures, she was able to conduct her further research.

Having successfully completed her postgraduate studies in 1962, R. Ganieva began her work in the Department of Tatar Literature at Kazan State University. Here, she went from an assistant professor to a full professor. Over 50 years of her work in the department, Reseda Kadyrovna became a prominent scholar who was engaged in contextual and comparative studies of various periods of the Tatar literature history. She researched Eastern and Arabic literature, giving scientific and theoretical substantiation of traditions and innovations in verbal art. She also explored the methods used in teaching Tatar

literature, the terms and concepts, revealing the inner nature of literary trends, and studied the features characterizing the artistic thinking of dozens of writers.

Reseda Ganieva was a teacher and mentor who greatly influenced the lives of thousands of students. Her lectures and seminars were a school in their own right. Rezeda Kadyrovna's love for the art of the word, her deep knowledge and comprehension of its innermost secrets aroused in her students genuine interest in scientific research. She was an experienced and highly qualified lecturer. Even in the times when the pressure of Soviet ideology was strong, she taught her students the skills of spiritual freedom, the objective approach to literary phenomena, free from any bias when studying and evaluating literature.

The personal qualities of R. Ganieva were reflected in her scientific research. She stood out among her colleagues for her integrity and factuality. Her works had a firm scientific and theoretical basis, characterized by richness of the factual material and deep respect for her predecessors' achievements, which accounts for the great value of her scientific work today.

The young scientist began her first scientific study with the work about Tukay. She successfully defended her PhD thesis devoted to the study of the great poet's satirical works in the context of the literary movement of that time. Her study "Satirical Works of G. Tukay" (1964) was a serious scientific novelty in Tatar literary criticism [1]. The author focused on the disclosure of the aesthetic value of Tukay's works. Her findings concerning the history of the poet's writing, the conditions that influenced his work, as well as the impact of Eastern and Arabic literature on Tukay's thoughts aroused great interest in the literary community. It should be noted that the theme of Tukay remained the focus of R. Ganieva's attention throughout her life [2, p. 171]. R. Ganieva wrote that the poet was the one who radically changed Tatar poetry, raised it to the level of world literature, and had a huge impact on late Tatar literature, on the art of the Turkic word. "The scholar upheld the greatness of Tukay's work, exploring its ideological and semantic depth, philosophical and aesthetic nature and the figurative embodiment of poetic thinking, which ensured the revival and development of Tatar poetry at a new level" [3, p. 158], writes T. Gilazov.

Whatever period of national verbal art Rezeda Kadyrovna studied later, she connected it with the great Tukay, for the poet worked on the literary and aesthetic values of the centuries-old Turkic-Tatar literature, which, like the traditions of Tukay, served as a source of inspiration for poets of different generations, a model of artistic skills. R. Ganiyeva considered Tukay to be a folk poet who creatively absorbed the achievements of Eastern and Russian-European literature, developed in our national traditions, in our native land, and this conception opened the way to numerous new studies. In her work "The Spiritual World of Tukay" (2002) [4], as well as in dozens of articles in the "Encyclopedia of Gabdulla Tukay" (2016) [5], the poet's work is assessed in the context of public life, Islam, the Tatar Renaissance and the changes that took place in the literary process of that time, its significance for the national culture of its time and modernity.

The study of the enormous creative heritage of the national poet aroused R. Ganieva's interest in the theory of literature. In the 1970s–1980s, the search for new ways of studying verbal art began in the country, and the interest in literary trends, principles, methods, genres and styles was on the increase. The scholar's research on the characteristic features of Tukay's artistic thinking led her to the scientific issue of creative methods used in Turkic literature. As a result, "The Creative Method of Tukay (in relation to the evolution of romantic tendencies)" (1972) [6], "Issues of the Creative Method in Turkic Literature" (1979) [7] and other works enriched and complemented the studies of N. Gulyaev, Kh. Gusman, I. Nurullin , J. Nigmatullina, et al.

A special place in R. Ganiyeva's studies is occupied by her studies of the art of the word in the early twentieth century. The scholar, following the views of Z. Validi, G. Sagdi, G. Nigmati, considerd this period to be the second Renaissance of Tatar literature, that is, the continuation of the Turkic Renaissance traditions, formed in new conditions under the strong influence of the Eastern Renaissance. Linking its beginnings with the activities of the enlightenment movement and its prominent representatives K. Nasyri, Sh. Marjani, she examined the work of the major figures of Tatar literature in the early twentieth century: F. Amirkhan, G. Ibragimov, N. Dumavi, Sh. Kamal, S. Ramiev, Sh. Babich and others. In this regard, the beginning of the twentieth century put an end to many discussions, indicating the main features of Tatar verbal art, in particular, that Enlightenment realism gave way to critical realism, Eastern romanticism was replaced by

European romanticism; in addition to these, classical trends, such trends of modernism as symbolism, existentialism, expressionism, impressionism and acmeism were also typical of this period.

The scholar's research, relating to the early the 20th century, is complemented by the works devoted to G. Iskhaki. After ideological and political restrictions on the studies of the past were removed, R. Ganieva, together with the students, took up research into the textological and literary-aesthetic aspects of Iskhaki's work, the author who became "an outstanding prose writer, playwright, publicist and leader of the national liberation movement" [p. 8, 6]. Her colleagues, I. Nurullin, G. Makhmutov, L. Gainanova, A. Sakhapov, F. Musin, Kh. Minnegulov, M. Khasanov, A. Akhmadullin, F. Galimullin and others, continuing research in this area, interpreted G. Iskhaki's work as an integral phenomenon in the context of centuries-old traditions of Tatar literature. In the course curriculum "The Work of Gayaz Iskhaki" for students of Tatar literature, R. Ganiyeva, conducting a detailed study and evaluation of his numerous works, highlighted the periods of "enlightenment", "tanchylyk (the period when he was fascinated by revolutionary ideas)", "nationalism", "emigration", indicating the qualitative changes that determined the essence of each period. The conceptual novelty of G. Iskhaki's work and the methods for studying it, emphasized in this curriculum, are scientific findings that are still valued today [9, p. 260].

The work of R. Ganiyeva "Eastern Renaissance and the poet Kul Gali" (1988) [10] and the doctoral dissertation "Eastern Renaissance and its traditions in Turkic literatures", defended on its basis in 1992 [11], enriched Tatar literary studies with new scientific ideas and results. Studying the features of the Eastern Renaissance, the scholar points to the strong influence of this artistic period on the Turkic Renaissance. In her opinion, "The Legend of Yusuf" by Kul Gali was a poem created under the influence of Arab-Muslim philosophy [12, p. 180]. She emphasized that the Bulgar writer, relying on the philosophy of monotheism (at-Tawhid), depicted a person in the center of the universe. She came to the conclusion that the connection between the inner and outer beauty of the personality, their feelings and mind were a synthesis of moral and Sufi views. Evaluating Kul Gali's famous story as a work that marked the beginning of the Tatar revival, she noted its rich traditions.

The monographs of Reseda Kadyrovna "Tatar Literature: Traditions and Relationships" (2002) [13], "Traditions of the Eastern Renaissance in the Turkic Literatures of the Middle Ages and Modern Times" (2014) [14], which became a continuation of the abovementioned studies, reveal the development of national verbal art in close relationship with the literatures of the Turkic peoples. R. Ganieva explored, in terms of traditions and socio-social contradictions of that time, the spiritual heritage of such writers as Mukhammadyar, Maulya Kuliy and G. Utyz Imani who were out of sight of the contemporary literary community. In his poems, Muhammadyar, the 16th century poet, highlighted the signs of the Turkic Renaissance, elevated the human personality, defending the justice of the relationship between the judge and the people and other universal values. Noting the inconsistency of the works by M. Kulyi, who lived and worked in the 17th century, she discovered that universal ideals were hidden behind his religious and Sufi views. In his works, along with an idea of brevity of life and a warning about inevitability of death, she found such motifs as patience and generosity, a desire for family happiness, and the glorification of the farmer's work. G. Utyz-Imani was regarded as a supporter of the need for religious and secular education. According to R. Ganieva, this writer's work was also a contradictory one, he put religious science above secular science and through it, he called for knowing the world, for the improvement of the reader's morality and patience.

Along with her research into the works of the Tatar writers from different eras (Y. Balasaguni, Mukhammadyar, M. Kuly, G. Utyz-Imani, K. Nasyri, R. Fakhretdin, G. Tukay, G. Iskhaki, F. Amirkhan, Sh. Babich, G. Taktash, H. Tufan, M. Jalil, S. Hakim, R. Gatash, M. Mirza), R. Ganieva made a significant contribution to the study of the heritage of outstanding Turkic and Slavic writers of the peoples from the Volga and Ural regions. Her articles, devoted to the work of Ukrainian T. G. Shevchenko, Russian M. M. Kheraskov, Azerbaijanis Vagif, Vazekh and Sabir, Kazakh Abai, Turkmen Makhtumkuli, Chuvash M. Sespel and others, express deep respect for the verbal art of these peoples. The scholar enriched the study and comparative- historical evaluation of literature with new ways and methods.

"She was a mentor who created her own scientific school in the field of the Eastern cultural movement revival, developed new creative methods in literary studies and established new

interliterary relations" [15, p. 175], she brought numerous students, graduate students and colleagues to the world of science, and they willingly shared her deep knowledge. R. Ganieva, her way of life and personal qualities, was an example of a real teacher, mentor and personality. The numerous works of the scholar, characterized by scientific and theoretical depth, rich philosophical and aesthetic content, raised the Tatar literary science to a new level, laying the foundations for new research, today they are an important spiritual heritage.

**References**

1. Ganiyeva, R. (1964). *Satiricheskoye tvorchestvo G. Tukaya* [Satirical Works of G. Tukay]. Kazan', izd-vo KGU. (In Russian)

2. Yusupova, N. M. (2017). *Zhizn', posvyashchennaya nauke* [Life Dedicated to Science]. Volga. No. 11, pp. 66–67. (In Russian)

3. Gilazov, T. Sh. (2008). *Osnovnye tendentsii razvitiya tukayevedeniya na rubezhe XX – XXI vekov* [The Main Tendencies of Tukay's Poetry Studies at the Turn of the $20^{th}$ – 21st Genturies]. Uchenye zapiski Kazanskogo gosudarstvennogo universiteta. Tom 150, Kniga 8, Seriya Gumanitarnye nauki, pp. 42–47. (In Russian)

4. Ganiyeva, R. (2002). *Dukhovnyi mir poeta (po materialam entsiklopedicheskogo slovarya-spravochnika "Gabdulla Tukay")* [Spiritual World of the Poet (based on the encyclopedic dictionary-reference book "Gabdulla Tukay")]. Kazan', Istoriya. (In Russian)

5. *Gabdulla Tukay. Entsiklopediya* (2016)[ Gabdulla Tukay. Encyclopedia]. Sost. Z. Z. Ramiyev. 864 p. Kazan', Institut yazyka, literatury i iskusstva im. G. Ibragimova. (In Russian)

6. Ganiyeva, R. (2002). *Tvorcheskii metod Tukaya (k evolyutsii romanticheskikh tendentsii)* [Tukay's Creative Method (on the evolution of romantic tendencies)]. Dukhovnyi mir poeta (po materialam entsiklopedicheskogo slovarya-spravochnika "Gabdulla Tukay"). Pp. 65–85. Kazan', Istoriya. (In Russian)

7. Ganiyeva, R. (1979). *Voprosy metoda tvorchestva v tyurkskoi literature* [Issues of the Method of Creativity in Turkic Literature]. Aktual'nye voprosy sovremennogo tatarskogo literaturovedeniya. Pp. 97–105. Kazan'. (In Russian)

8. Ganiyeva, R. K. (2005). *Tvorchestvo Gayaza Iskhaki* [Gayaz Iskhaki's Work]. Kazan', Kazanskii gosudarstvennyi universitet. (In Russian)

9. Zakirzyanov, A. M. (2011). *Velikaya doch' Maloi Shygyrdan* [The Great Daughter of Maloy Shygyrdan]. Dukhovnaya opora: literaturno-kriticheskiye stat'i. Pp. 256–261, Kazan', Tatar.kit.izdaniye. (In Russian)

10. Ganiyeva, R. K. (1988). *Vostochnyi Renessans i poet Kul Gali* [Eastern Renaissance and the Poet Kul Gali]. Kazan', izd-vo Kazan. un-ta. (In Russian)

11. Ganiyeva, R. (1992). *Vostochnyi Renessans i yego traditsiya v tyurkskikh literaturakh: diss ... dokt. filol. nauk* [Oriental Renaissance and Its Tradition in Turkic Literatures: Doctoral Thesis]. (In Russian)

12. Sayapova, A. M. (2017). *Yubilei uchitelya* [Jubilee of the Teacher]. Filologiya i kul'tura. No. 4, pp. 255–256. (In Russian)

13. Ganiyeva R. (2002). *Tatarskaya literatura: traditsii, svyazi* [Tatar Literature: Traditions and Connections]. Kazan', izd-vo universiteta. (In Russian)

14. Ganiyeva, R. (2014). *Traditsii Vostochnogo Renessansa v tyurkskikh literaturakh Srednevekov'ya i Novogo vremeni* [Traditions of the Eastern Renaissance in Turkic Literatures of the Middle Ages and Modern Times]. Kazan', izd-vo "Nauka" AN RT. (In Russian)

15. Zagidullina, D. F. (2017). *Miry, otkrytyye uchenym* [Worlds, Discovered by Scientists]. Ogni Kazani. No. 11, pp. 171–176. (In Russian)

# КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫН САЛЫП…
# (РЕЗЕДА ГАНИЕВАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ)

**Әлфәт Мәгъсүмҗан улы Закирҗанов,**
ТР ФАнең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 420111, Казан ш., К. Маркс ур., 12 нче йорт,
alfat_zak@mail.ru.

XX гасырның 60 елларыннан башлап, татар әдәбият белеме өлкәсендә җитди тикшеренүләр алып барган, аның методологиясен, принцип-методларын ачыклауга, яңа эзләнү юнәлешләрен билгеләүгә зур өлеш керткән, үзенең хезмәтләре белән Идел – Урал буе һәм төрки халыкларның әдәбиятлары фәнендә киң танылу алган галимнәрнең берсе – Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор Резеда Кадыйр кызы Ганиева. Галимәнең тууына 90 ел тулу датасы, аның тормыш һәм иҗат юлын, шәхес сыйфатларын, фәнни табышларын тагын бер кат күздән кичереп, аларның үз вакытында

һәм бүгенге көн әдәбият фәнендә кыйммәтен билгеләү мөмкинлеге бирә.

Р. К. Ганиева 1932 елның 13 ноябрендә Казан артындагы Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылында туа. Бөек Ватан сугышы башланып, әтисе Габделкадыйр фронтка киткәндә, аңа 9 яшь тулмаган була. Ленинград өчен барган канлы сугышларның берсендә әтисенең һәлак булуы турындагы кайгылы хәбәр авылларында беренче булып аларга килә. Дүрт бала белән тол калган Хәбирә апа балаларын ач үлемнән саклап калу, укыту, һөнәрле итү өчен барысын да эшли. Олы кыз буларак Резедага бик иртә тормыш «арба»сын тартырга туры килә. Үткен, чая яшүсмер, авырлыкларга баш имичә, зур максатлар куеп укый. Туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан педагогия училищесына укырга керә һәм иң алдынгы укучыларның берсе булып таныла. Мәктәп елларында киңәш-табышлары белән ярдәм иткән укытучылары Зифа һәм Наил Гобәйдуллиннарны, училищеда укыганда шәхес һәм остаз буларак соклану уяткан Вәли Хаҗиевны, Разия Баязитованы һ.б.ларны гомере буе сагынып искә ала.

Педагогия училищесы дипломы белән берничә ел Казан һәм Биектау районы Мүлмә авылы мәктәбендә балалар укыта. Шул чорда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып белем ала. Остазы профессор И. Нуруллин киңәше белән Мәскәү университетының СССР халыклары әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурага укырга керә һәм Г. Тукай иҗатында сатира темасын өйрәнә башлый. Монда Р. Ганиева үзе өчен яңа дөнья ача. Фәнни җитәкчесе Мәдинә Искәндәр кызы Богданова, шулай ук кафедраның танылган галимнәре И. С. Брагинский, Х. Г. Кер-Оглы, А.И. Климович, Р. Г. Бикмөхәммәтов, А. А. Шәрәф һ.б. лекцияләрен тыңлау, даими аралашу аның фәнни офыкларын, кызыксынуларын киңәйтә. Үзе белән бергә укыган аспирантлар ярдәме белән башкорт, чуваш, кыргыз, азәрбайҗан, коми, якут әдәбиятларын өйрәнү дә киләчәк тикшеренүләренә нигез була.

Аспирантураны уңышлы тәмамлап, Р. К. Ганиева 1962 елда Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасына эшкә алына. Монда ул ассистенттан алып профессор дәрәҗәсенә кадәр хезмәт юлы үтә. Кафедрада 50 елга якын эшләү дәверендә Резеда Кадыйр кызы татар әдәбияты тарихының төрле чорларын, Шәрык һәм Гареб әдәбиятлары контекстында һәм чагыштырма планда тикшергән, сүз сәнгатендәге традицияләрне һәм яңачалыкларны, термин-төшенчәләрне фәнни-теоретик нигезләгән, татар әдәбиятындагы әдәби юнәлеш, агым, методларның эчке хасиятләрен ачып, дистәләгән әдипнең сәнгати фикерләү үзенчәлеген өйрәнгән зур галимә булып таныла.

Резеда Ганиева – меңләгән студентларның тормышта үз урыннарын табуына зур өлеш кертән укытучы-остаз да. Аның лекция-семинарлары үзе бер мәктәп булып тора. Резеда Кадыйр кызының сүз сәнгатенә мәхәббәте, аны яхшы белү һәм эчке серләренә төшенү омтылышы укучыларында да фәнни тикшеренү эшенә кызыксыну уята. Ул югары дәрәҗәдәге оста лектор. Совет идеологиясе басымы көчле булган чорларда да шәкертләрендә рухи ирек, әдәби күренешләргә объектив якын килү, әдәбиятны һәртөр конъюнктурадан азат итеп өйрәнү һәм бәяләү күнекмәләре тәрбияли.

Р. Ганиеваның шәхси сыйфатлары фәнни тикшеренүләренә дә йогынты ясый. Ул коллегалары арасында принципиальлеге, фактларга һәм дәлилләргә нигезләнүе белән аерылып тора. Хезмәтләренең фәнни-теоретик нигезенең ныклыгы, фактик базасының байлыгы, үзенә кадәрге галимнәргә тирән хөрмәте гыйльми эшчәнлегенең кыйммәтен бүген дә саклый.

Яшь галимә тәүге фәнни тикшеренүләрен Тукай иҗаты белән башалап җибәрә. Бөек шагыйрьнең сатирик әсәрләрен шул чор әдәби хәрәкәте яссылыгында өйрәнүгә багышланган кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. «Сатирическое творчество Г. Тукая» («Г. Тукайның сатирик иҗаты») (1964) хезмәте татар әдәбияты белеме фәненә җитди фәнни яңалык алып килә [1]. Автор үз игътибарын Тукай әсәрләренең эстетик кыйммәтен ачуга юнәлтә. Аларның язылу тарихын, шагыйрь каләменә йогынты ясаган шартларны, шулай ук Шәрык һәм Гареб әдәби фикеренең Тукайга тәэсирен ачудагы табышлары әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Әйтергә кирәк, Тукай темасы галимәнең гомерлек юлдашы булып кала [2, 171 б.]. Р. Ганиева шагыйрьне татар поэзиясен тамырдан үзгәртеп, дөнья әдәбияты дәрәҗәсенә күтәргән, үзеннән соңгы татар әдәбиятына, төрки халыклар сүз сәнгатенә гаять зур йогынты ясаган әдип дигән нәтиҗә ясый. «Галимә үз игътибарын, яңа кимәлдә иҗат итеп, татар шигъриятенең яңарышын һәм үсешен тәэмин иткән Тукай

иҗатының фикри-мәгънәви тирәнлеген, фәлсәфи-эстетик табигатен һәм шигъри фикерләвенең сурәтле-бизәкле гәүдәләнешен тикшереп, аның бөеклеген һәм даһилыгын раслауга юнәлтә» [3, с. 44], – дип яза Т. Гыйлаҗев.

Резеда Кадыйр кызы алга таба милли сүз сәнгатенең кайсы гына чорын өйрәнсә дә, аны бөек Тукайга китереп тоташтыра, чөнки шагыйрь күпгасырлык төрки-татар әдәбиятындагы әдәби-эстетик кыйммәтләрне фокус рәвешендә үз иҗатында туплаган булса, соңрак алар, Тукай традицияләре буларак, төрле буын шагыйрьләренә илһам чыганагы, сәнгати осталык үрнәге булып хезмәт итә. Р. Ганиева Тукайны, шәрык һәм рус-европа әдәбиятлары казанышларын иҗади үзләштереп, милли традицияләребездә, үз җирлегебездә формалашкан халыкчан шагыйрь дип саный һәм аның әлеге концепциясе күпсанлы яңа тикшеренүләргә юл ача. Галимәнең «Тукайның рухи дөньясы» (2002) [4] хезмәтендә, шулай ук «Габдулла Тукай энциклопедиясе»нә (2016) [5] язылган дистәләрчә мәкаләсендә шагыйрь иҗаты иҗтимагый яшәеш, ислам дине, татар Яңарышы һәм шул чор әдәби процессында барган үзгәрешләр контекстында бәяләнә, үз чоры һәм бүгенге милли мәдәният өчен әһәмияте билгеләнә.

Халык шагыйренең гаять бай иҗат мирасын тикшерү Р. Ганиеваны әдәбият теориясе белән кызыксынуга китерә. 1970–1980 елларда ил күләмендә сүз сәнгатен өйрәнүнең яңа юлларын эзләү, әдәби юнәлеш-агымнар, принцип-методлар, жанр-стильләр белән кызыксыну арта. Тукайның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге белән кызыксыну галимәнең игътибарын төрки әдәбиятлардагы иҗат методлары фәнни проблемасына юнәлтә. Нәтиҗәдә «Тукайның иҗат методы (романтик тенденцияләр эволюциясенә карата)» (1972) [6], «Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре» (1979) [7] һ.б. хезмәтләре Н. Гуляев, Х. Госман, И. Нуруллин, Й. Нигъмәтуллина һ.б. тикшеренүләрен баета һәм тулыландыра.

Р. Ганиева хезмәтләрендә XX йөз башы сүз сәнгате аерым урын алып тора. Галимә, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Нигьмәти карашларын дәвам итеп, бу дәверне татар әдәбиятындагы икенче Яңарыш чоры, ягъни Шәрык Яңарышының көчле йогынтысында формалашкан төрки Яңарышы традицияләренең яңа шартларда дәвам итүе дип карый. Башлангычын мәгърифәтчелек хәрәкәте, аның күренекле вәкилләре К. Насыйри, Ш. Мәрҗани эшчәнлеге белән бәйләп, XX йөз башы татар әдәбиятының төп көчләре булган Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Н. Думави, Ш. Камал, С. Рәмиев, Ш. Бабич һ.б. иҗатын Яңарышка нисбәтле тикшерә. Шуларга бәйле XX йөз башы татар сүз сәнгатенең төп хасиятләрен, аерым алганда, мәгърифәтчелек реализмының үз урынын тәнкыйди реализмга бирүен, Шәрык романтизмының Европа романтизмы белән алышынуын, әлеге классик юнәлешләрдән тыш бу чорда модернизмның символизм, экзистенциализм, экспрессионизм, импрессионизм, акмеизм кебек агымнарының үзенчәлекләре, тасвирый алымнары һәм образлары кулланылышын дәлилләп, күп кенә бәхәсләргә нокта куя.

Галимәнең XX йөз башына караган эзләнүләре Г. Исхакый иҗаты белән тулылана. Җәмгыятьтә фикер төрлелегенә юл ачылып, үткәннәргә карата идеологик һәм сәяси чикләүләр алып ташлангач, Р. Ганиева студентлары белән бергә, «яңа заман татар Ренессанс әдәбиятының нигез ташларын салучы атаклы прозаик, драматург, публицист һәм милли азатлык хәрәкәте юлбашчысы» [8, 6 б.] булган әдип иҗатын текстологик һәм әдәби-эстетик яссылыкта тикшерүгә алына. Хезмәттәшләре И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова, Ә. Сәхапов, Ф. Мусин, Х. Миңнегулов, М. Хәсәнов, А. Әхмәдуллин, Ф. Галимуллин һ.б. бу өлкәдәге эзләнүләрен дәвам итеп, Г. Исхакый иҗатын бербөтен күренеш буларак күпгасырлык татар әдәбияты традицияләре контекстында шәрехли. Студентлар өчен әзерләнгән «Гаяз Исхакый иҗаты» («Творчество Гаяза Исхаки») (2005) программасында күпсанлы әсәрләрне җентекле өйрәнү һәм бәяләү аша әдип иҗатында «мәгърифәтчелек», «таңчылык», «милләтчелек», «мөһаҗирлек» чорларын аерып чыгара, һәрберсенең асылын билгеләгән сыйфат үзгәрешләренә тукталa. Г. Исхакый иҗатының әлеге программада ассызыклап күрсәтелгән концептуаль яңалыгы һәм аны өйрәнү юллары бүген дә кыйммәтен югалтмаган фәнни табышлар булып тора [9, 260 б.].

Р. Ганиеваның «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» (1988) [10] хезмәте һәм шуның нигезендә 1992 елда якланган «Шәрык Ренессансы һәм төрки халыклар әдәбиятларында аның традицияләре» («Восточный Ренессанс и его традиции в тюркских литературах») [11] докторлык диссертациясе татар әдәбияты турындагы

фәнне яңа гыйльми күзаллаулар һәм нәтиҗәләр белән баета. Галимә, Шәрык Яңарышы үзенчәлекләрен өйрәнү аша, әлеге сәнгати күренешнең төрки Яңарышка көчле йогынты ясавын дәлилли һәм Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен гарәп-мөселман фәлсәфәсе тәэсирендә иҗат ителгән поэма буларак тикшерә [12, с. 180]. Болгар чоры әдибенең бераллалык (әт-Тәүхид) фәлсәфәсенә таянып, кешене галәм үзәгенә куеп сурәтләвен ассызыклый. Шәхеснең эчке һәм тышкы матурлыгын, хисе һәм акылы бәйләнешен әхлакый һәм суфичыл карашлар синтезы буларак каравы турындагы нәтиҗәгә килә. Кол Галинең атаклы кыйссасын татар Яңарышын башлап җибәрүче әсәр төсендә бәяләп, аның гаять бай традицияләргә нигез салуын билгели.

Резеда Кадыйр кызының югарыдагы эзләнүләренең дәвамы буларак дөнья күргән «Татар әдәбияты: традицияләр, бәгланышлар» (2002) [13], «Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени» (2014) [14] монографияләре, күпгасырлык татар әдәбиятын иңләп алып, милли сүз сәнгатенең үсешен төрки халыкларның әдәбиятлары белән тыгыз, үзара йогынтылы бәйләнештә ачалар. Р. Ганиева ул чорда әдәби җәмәгатьчелек күзеннән читтәрәк калып килгән Мөхәммәдъяр, Мәүла Колый, Г. Утыз Имәни кебек әдипләр рухи мирасын традицияләргә һәм чорның иҗтимагый-социаль каршылыкларына нисбәтле тикшерә. XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдъяр поэмаларында төрки Яңарыш билгеләрен аерып чыгара, кеше шәхесен зурлавы, хөкемдар һәм халык мөнәсәбәтенең гаделлеккә нигезләнүе һәм башка гомумкешелек кыйммәтләрне яклавы белән аның олы гуманист булуын дәлилли. XVII гасырда яшәп иҗат иткән М. Колый иҗатының каршылыклы булуын билгеләп, әдипнең дини-суфичыл карашлары артында гомумкешелек идеаллары ятуын ача. Әсәрләрендә гомер кыскалыгы, үлемнең якынлыгы турындагы кисәтү белән бергә, сабыр һәм юмарт булу, гаилә бәхетенә омтылу, игенче хезмәтен зурлау кебек мотивлар урын алуын күрсәтә. Г. Утыз Имәнине исә галимә дини һәм дөньяви белем кирәклеген яклап чыгучы буларак бәяли. Аның фикеренчә, әдип иҗаты әле каршылыклы, ул дөньяви гыйлемнән бигрәк дини гыйлемне алга куя, аның аша дөньяны танып белүгә, укучы әхлагын савыктыруга, сабырлыкка чакыра.

Р. Ганиева татар әдәбиятының төрле чорларына караган әдипләр (Й. Баласагунлы, Мөхәммәдъяр, М. Колый, Г. Утыз Имәни, К. Насыйри, Р. Фәхретдин, Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Ш. Бабич, Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, С. Хәким, Р. Гаташ, М. Мирза) иҗаты белән бергә, төрки, славян, Идел-Урал буе халыклары әдәбиятларының танылган әдипләре мирасын өйрәнүгә дә җитди өлеш кертә. Галимәнең украинлы Т. Г. Шевченко, рус М. М. Херасков, азәрбайҗанлы Вагиф, Вазех һәм Сабир, казакъ Абай, төрекмән Мәхтүмколый, чуваш М. Сеспель һ.б. иҗатларына багышланган язмаларында әлеге халыклар сүз сәнгатенә тирән хөрмәте чагыла, аларда иҗат әһелләре чагыштырма планда өйрәнелә. Галимә әдәбиятларны чагыштырма-тарихи планда өйрәнүне һәм бәяләүне яңа юллар һәм алымнар белән дә баета.

«Шәрык мәдәниятендә Яңарыш хәрәкәте, әдәбиятта иҗат методлары, яңа күренешләр һәм әдәбиятара бәгланышлар өлкәсендә үз фәнни мәктәбен булдырган остаз» [15, 175 б.] күпсанлы студентларны, аспирантларны, хезмәттәшләрен фән дөньясына алып керә, тирән белеме белән бик теләп уртаклаша. Хезмәтенә күңел җылысын салып, аның халкыбызга кирәклеген тирән аңлап эш итүе белән шәкертләрендә ачык тормыш позициясе, миһербанлык, ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияли. Р. К. Ганиева үзенең яшәү рәвеше, кешелек сыйфатлары белән чын Укытучы, Остаз, Шәхес булу үрнәген күрсәтте. Галимәнең фәнни-теоретик тирәнлеге, фактик байлыгы, фәлсәфи-эстетик эчтәлеге белән характерланган күпсанлы хезмәтләре татар әдәбият фәнен яңа биеклеккә күтәрде, яңа тикшеренүләргә нигез салды һәм алар бүген дә гаять әһәмиятле рухи мирас булып тора.

**Әдәбият**


1. *Ганиева Р.* Сатирическое творчество Г. Тукая. Казань: Изд-во КГУ, 1964. 84 с.
2. *Йосыпова Н.М.* Фәнгә багышланган гомер // Идел. 2017. № 11. Б. 66–67.
3. *Гилазов Т. Ш.* Основные тенденции развития тукаеведения на рубеже XX–XXI веков // Ученые записки Казанского государственного университета. Том 150. Книга 8. Серия Гуманитарные науки. 2008. С. 42 – 47.
4. *Ганиева Р.* Шагыйрьнең рухи дөньясы («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТаРИХ, 2002. 112 б.

5. Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш мөх. З. З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

6. *Ганиева Р.* Тукайның иҗат методы (романтик тенденцияләр эволюциясенә карата) // Шагыйрьнең рухи дөньясы («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 65–85.

7. *Ганиева Р.* Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре // Хәзерге татар әдәбияты белеменең актуаль мәсьәләләре. Казан, 1979. Б. 97–105.

8. *Ганиева Р. К.* Гаяз Исхакый иҗаты. Творчество Гаяза Исхаки. Казань: Казанский государственный университет, 2005. 38 с.

9. *Закирҗанов Ә. М.* Кече Шырданның олуг кызы // Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. Б. 256–261.

10. *Ганиева Р. К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. 172 с.

11. *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и его традиции в тюркских литературах: дис. ... докт. филол. наук, 1992. 325 с.

12. *Саяпова А. М.* Юбилей учителя // Филология и культура. 2017. № 4. С. 255–256.

13. *Ганиева Р.* Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар. Казан: Университет нәшрияты, 2002. 272 б.

14. *Ганиева Р*. Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. Казань: Изд-во «Фән» АН РТ, 2014. 272 с.

15. *Заһидуллина Д. Ф.* Галимә ачкан дөньялар // Казан утлары. 2017. № 11. Б. 171–176.